**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 21 ноябрендәге 4109 номерлы карары**

**XXXIII Бөтенроссия «Россия студентлар язы» фестиваленә әзерләнү һәм аны уздыру чорында транспорт чаралары хәрәкәтен һәм аларны куеп торуны вакытлыча чикләү турында**

XXXIII Бөтенроссия «Россия студентлар язы» фестиваленә әзерләнү һәм аны уздыру чорында иминлекне тәэмин итү максатыннан, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 маендагы 372 номерлы «Төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә туктатып торуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында»гы карары нигезендә:

1. **Карар бирәм**:

1.1. түбәндәге участокларда, ихтыяҗ булганда, транспорт чаралары хәрәкәтен һәм аларны куеп торуны вакытлыча чикләүне кертергә:

1.1.1. 2025 елның 25 һәм 28 ноябрендә 07.00 сәгатьтән 23.59 сәгатькә кадәр Спартак урамы буйлап, Һади Такташ урамыннан Артем Айдинов урамына кадәр;

1.1.2. 2025 елның 25 һәм 28 ноябрендә 07.00 сәгатьтән 23.59 сәгатькә кадәр Артем Айдинов урамы буенча, Островский урамыннан Марсель Сәлимҗанов урамына кадәр;

1.2. Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитетына (А.В.Сидоров):

1.2.1. вакытлыча юл билгеләрен урнаштыру һәм гамәлдәге юл билгеләрен каплау буенча чаралар оештырырга;

1.2.2. транспорт чаралары хәрәкәтен һәм аларны куеп торуны вакытлыча чикләү турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы рәсми порталы» дәүләт мәгълүмат системасы составына керә торган рәсми сайтында урнаштырырга;

1.2.3. кыска вакытлы аренда хезмәте күрсәтә торган электр самокатлары (WHOOSH һәм МТС.URENT) һәм велосипедлар («Яшел шәһәр») операторлары белән берлектә әлеге карарда күрсәтелгән участокларда шәхси мобильлек чараларын куеп торуны һәм аларның хәрәкәтен тыю буенча эшне оештырырга;

1.3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитетына (А.М.Шайнуров) Казан шәһәре Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе (А.И.Салихов) белән берлектә юлларны йөк техникасы яки таранга каршы блоклар белән ябу эшен оештырырга;

1.4. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

2. **Тәкъдим итәм:**

2.1. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенә (Р.Д.Габитов) әлеге карар нигезендә Казан шәһәре урам-юл челтәренең югарыда күрсәтелгән участокларында юл хәрәкәте иминлеген саклауны һәм оештыру-көйләү гамәлләрен башкаруны контрольдә тотуны тәэмин итәргә;

2.2. Казан шәһәре Думасы аппаратының Мәгълүмат-аналитика идарәсенә (В.А.Казанцев) урам-юл челтәренең күрсәтелгән участокларында транспорт чаралары хәрәкәтен һәм аларны куеп торуны вакытлыча чикләүне кертү турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша хәбәр итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка **йөклим**.

**Җитәкче вазифаларын**
**башкаручы – урынбасар** **И.В.Куляжев**